КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 13 июль г.Казань № 587

Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ яшь гаиләләргә торак урыннары бирү тәртибен раслау турында

«Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ яшь гаиләләргә торак урыннары бирү тәртибен расларга.

2. Торак урыннары бирү буенча вәкаләтле оешма булып «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә билгеләнә торган махсуслаштырылган оешма тора дип билгеләргә.

3. Социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ яшь гаиләләргә бирү өчен билгеләнгән торак урыннары махсуслаштырылган оешманың попечительләр советы белән килештерелгән күләмдә бүлеп бирелә дип билгеләргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 13 июль, 587 нче
карары белән расланды

# Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ яшь гаиләләргә торак урыннары бирү тәртибе

1. Бу Тәртип социаль ипотека системасында яшь гаиләләргә торак урыннары бирү юлы белән торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү механизмын билгели.

2. Бу Тәртиптә кулланыла торган төп төшенчәләр:

яшь гаилә – иренең йә хатынының яше 35 яшьтән артмаган, шул исәптән тәрбияләүгә алынган баласы (балалары) булган, никахлары теркәлгән гаилә яки яше 35 яшьтән артмаган, тәрбияләүгә алынган баласы (балалары) булган, бер ата-анадан торган, тулы булмаган гаилә (алга таба – яшь гаилә);

махсуслаштырылган оешма – «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә аны турыдан-туры тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан төзелгән яки вәкаләт бирелгән республика коммерциягә карамаган оешмасы яки орган;

гариза бирүче – Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче, социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ яшь гаиләне исәпкә кую максаты белән әгъзасы булган яшь гаилә исеменнән «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнгән тәртиптә гариза бирүче Россия Федерациясе гражданы;

гариза бирүченең гаилә әгъзалары – гариза бирүче белән бергә яшәүче аның балалары һәм ире (хатыны);

социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ яшь гаиләне исәпкә кую нормасы – торак хокуклары объектларында гариза бирүче гаиләсенең бер әгъзасына туры килә торган гомуми мәйданның күләме;

алдан җыела торган акча – төзелеш объектын эксплуатацияләүгә тапшырганга кадәр өстенлекле сайлап алу хокукында өлешләп фатир сатып алу максаты белән гариза бирүче тарафыннан җыелып бара торган акча. Алдан акча җыю тәртибе ирекле булып тора һәм гариза бирүченең үзе тарафыннан фатирны сайлап алуның өстенлекле хокукыннан файдалану нияте булганда, шулай ук алдан җыела торган акчаны махсуслаштырылган оешманың исәп-хисап счетына кертү шарты белән айлык түләүләрне өлешләп түләү вакытын озайту мөмкинлеге белән билгеләнә;

беренчел кертем – гариза бирүче тарафыннан социаль ипотека шартнамәсе (алга таба – шартнамә) төзегән вакытка кертелә торган, катнашучының фатир сатып алу хокукын тәэмин итә торган акча.

3. Социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ яшь гаиләне исәпкә кую түбәндәге шартларны үтәп гамәлгә ашырыла:

гаиләнең һәр әгъзасына гомуми яшәү минимумын тәэмин итә торган һәм торак урыннарын милеккә сатып алу буенча айлык агымдагы түләүләрне үз вакытында каплауны гарантияли торган гаиләнең бер әгъзасына айлык җыелма керем булу;

торак хокуклары объектларында гариза бирүче гаиләсенең бер әгъзасына гомуми мәйдан белән тәэмин ителешнең җыелма дәрәҗәсе 18 квадрат метрдан кимрәк булу;

яшь гаиләнең торак белән гражданнарның аерым категорияләрен тәэмин итүгә юнәлдерелгән федераль һәм республика программалары буенча элегрәк сатып алынган торак урын бәясен түләү буенча, шул исәптән махсуслаштырылган оешма белән элегрәк төзелгән шартнамә буенча максатчан акчалата заемны тулысынча кире кайтару буенча йөкләмәләре булмау.

4. Гариза бирүче теркәлү урыны буенча җирле үзидарә органнарына, бу Тәртипкә теркәлгән 2 нче кушымтадагы исемлек буенча нигезли торган документларны күрсәтеп, әлеге Социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ яшь гаиләне исәпкә кую турындагы тәртипкә теркәлгән 1 нче кушымтадагы формада буенча гариза бирә һәм, бу Тәртипкә теркәлгән 3 нче кушымтадагы форма буенча барлык кирәкле мәгълүматларны күрсәтеп, гариза бирүче анкетасын тутыра. Гариза бирүчегә бу документларны алу турында, аларның исемлеген һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан алу датасын күрсәтеп, расписка бирелә.

Гражданнарның социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ яшь гаиләне исәпкә кую турындагы гаризаларын карап тикшерү җирле үзидарә органнары тарафыннан гариза бирелгән көннән 30 көн эчендә гамәлгә ашырыла.

5. Җирле үзидарә органнары исәпкә алу эшен формалаштыра, гариза бирүчеләрнең гаризаларын иҗтимагый торак комиссиясендә карап тикшерә һәм социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ яшь гаиләне исәпкә кую турында яисә аны исәпкә куюдан баш тарту турында карар чыгара.

Гариза бирүченә түбәндәге очракларда исәпкә куюдан баш тартыла:

бу Тәртипнең 2 нче пунктында билгеләнгән «яшь гаилә» төшенчәсенә туры килмәгәндә;

бу Тәртипнең 3 нче пунктында билгеләнгән шартлар нигезендә социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ яшь гаиләне исәпкә кую хокукын расламый торган документлар тапшырылганда;

бу Тәртипкә теркәлгән 2 нче кушымтада бирелгән исемлек буенча гаризага теркәлә торган кирәкле нигезләү документлары булмаганда һәм алар тулысынча тутырылмаганда;

гаризада һәм тапшырылган документларда күрсәтелгән мәгълүматларга туры килми торган дөрес булмаган мәгълүматлар ачыкланганда.

Исәпкә алу эшен теркәү өчен нигез булып җирле үзидарә органы җитәкчесенең гариза бирүчегә уникаль исәпкә алу коды бирелгән боерыгы тора.

Җирле үзидарә органы җитәкчесе социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ яшь гаиләнең исәпкә алу эшен теркәү турындагы

боерыгы күчермәсен һәм, гариза бирүче анкетасы нөсхәсен теркәп, яшь гаиләләр исемлеген җирле үзидарә органнары махсус оешмага җибәрә. Бу документларны тапшыру кәгазьдә һәм электрон рәвештә гамәлгә ашырыла.

6. Социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ яшь гаиләләрнең җирле исемлекләре җирле үзидарә органнары тарафыннан эш хәлендә (шул исәптән исемлекләрдән төшереп калдыру) даими нигездә алып барыла һәм тәэмин ителә.

7. Махсуслаштырылган оешма җирле үзидарә органнарыннан җирле үзидарә органы җитәкчесенең социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ яшь гаиләнең исәпкә алу эшен теркәү турындагы боерыгы күчермәсен, гариза бирүче анкетасы нөсхәсен кушып, яшь гаиләләр исемлеген кабул итә һәм 15 көн эчендә аларга анализ ясый һәм аларны махсуслаштырылган оешма реестрына кертү турында карар кабул итә һәм «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының әлеге законны үтәү йөзеннән кабул ителгән норматив хокукый актлары бозылган очракта, сәбәпләрен күрсәтеп, җирле үзидарә органнарына кире кайтара.

8. Махсуслаштырылган оешма реестры Татарстан Республикасының муниципаль районнары һәм шәһәр округлары яктылыгында төзелә.

9. Социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ яшь гаиләнең торак шартларын яхшырту хокукы махсуслаштырылган оешма реестрына кертелгән вакыттан барлыкка килә, бу турында махсуслаштырылган оешма гариза бирүчеләргә эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә, шулай ук махсуслаштырылган оешма реестрына кертү турында хәбәр алган көннән 90 көн эчендә махсуслаштырылган оешма белән шартнамә төзү кирәклеге турында хәбәр итә.

10. Яшь гаиләнең социаль ипотека системасында торак шартларын яхшырту хокукы барлыкка килгән вакыттан алып яшь гаилә махсуслаштырылган оешма реестрына кертү турындагы хәбәрнамәне алган көннән 90 көн эчендә махсуслаштырылган оешма белән шартнамә төзергә һәм чираттагы елга «Татарстан Республикасында гражданнарны торак белән тәэмин итү» программасы гамәлгә ашырыла торган ел алдыннан килә торган елның IV кварталына Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан раслана торган торакның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар кыйммәте күләменнән кимендә 11 процент күләмендә алдан җыелып бара торган акчаның айлык түләүләрен гамәлгә ашырырга тиеш.

11. Яшь гаилә, гаризада һәм документларда күрсәтелгән мәгълүматлар үзгәргәндә, 30 көн эчендә алар турында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ яшь гаиләне исәпкә алу урыны буенча җирле үзидарә органнарына язма рәвештә хәбәр итәргә тиеш.

12. Социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ яшь гаиләләр торак урын сайлап алу гамәлгә ашырыла торган календарь елда һәм фатир сайлап алу беркетмәсенә кул куйганга кадәр социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ яшь гаиләне исәпкә кую урыны буенча җирле

үзидарә органнарында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга дәүләт ярдәменә хокукын раслау максатларында яңадан теркәлергә тиеш.

Яңадан теркәлү шул ук социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ яшь гаилә исәпкә куела торган тәртиптә бу Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән гариза бирүченең яшен исәпкә алмыйча гамәлгә ашырыла.

Әгәр дә яшь гаилә социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ яшь гаиләне исәпкә кую датасыннан соң бер ел эчендә торак урын сайлауны башкарса, яңадан теркәлү таләп ителми.

13. Яшь гаиләнең махсуслаштырылган оешма реестрында тору хокукы, түбәндәге очраклардан тыш, аерым фатир сайлаганга кадәр саклана:

гаризада һәм исәпкә алу өчен нигез булучы тапшырылган документларда күрсәтелгән мәгълүматка туры килми торган мәгълүматлар ачыкланганда;

социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ яшь гаиләне исәпкә куйганда вазыйфаи затларның хокуксыз гамәлләре очраклары ачыкланганда;

Татарстан Республикасыннан читтә даими яшәү урынына барганда;

тәрбияләүгә алынган баласы (балалары) йә ата-ана хокукыннан мәхрүм ителгән яки уллыкка алу гамәлдән чыгарылган яшь гаилә тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә никах таркалганда;

гариза бирүченең һәм гаилә әгъзаларының исәптән төшерү турында шәхси гаризасы биргәндә;

яңадан теркәлү барышында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ яшь гаилә буларак хокукын расламый торган мәгълүматлар (бу Тәртипнең 12 нче пункты белән каралган очрактан тыш) ачыкланганда;

гариза бирүче махсуслашкан оешма реестрына кертү турында хәбәрнамә алган көннән 90 көн эчендә шартнамә төземәгәндә;

айлык түләүләрне гамәлгә ашыру буенча шартнамә шартлары үтәлмәгәндә;

якларның килешүе буенча шартнамәне өзүгә бәйле рәвештә махсуслаштырылган оешма реестрыннан төшереп калдырылганда.

Җирле үзидарә органнары, бу пунктта күрсәтелгән очраклар ачыкланганда, бу турыда махсуслаштырылган оешмага мондый очрак ачыкланган көннән 10 көн эчендә хәбәр итә.

Гариза бирүчене махсуслаштырылган оешма реестрыннан төшереп калдыру махсус оешма карары белән, карар кабул ителгән көннән 10 көн эчендә төшереп калдыруның сәбәбен күрсәтеп, тиешле җирле үзидарә органының мәҗбүри язма хәбәре белән гамәлгә ашырыла.

Махсуслаштырылган оешманың белдерүен алганнан соң җирле үзидарә органы 10 көн эчендә гариза бирүчене исәптән төшерү турында карар кабул итә. Исәптән төшерү турындагы карар гариза бирүченең исәптә тору өчен башка нигезләре булмаганда кабул ителә.

14. Социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ яшь гаиләләргә социаль ипотека буенча торак төзүгә бүлеп бирелә торган максатчан акча хисабына төзелгән торак йортларда фатирларны гражданнар категорияләре буенча бүлү ел саен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә торган квоталар нигезендә гамәлгә ашырыла.

15. Социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ яшь гаиләләргә бирелә торган торак урыннарның гомуми мәйданы нормативлары:

ике кешелек гаилә өчен – 42 квадрат метр;

өч һәм аннан да күбрәк кеше булган гаилә өчен – бер кешегә 18әр квадрат метр;

Казан, Яр Чаллы, Әлмәт, Түбән Кама, Зеленодольск, Алабуга шәһәрләрендә, Лаеш һәм Биектау муниципаль районнарында билгеләнгән ташламалы бәядән торак урыннар бирү нормативын арттыру 20 проценттан артыграк тәшкил итмәскә тиеш;

әгәр дә нормативның артуы 20 проценттан артыграк тәшкил итсә, нормативтан (шул исәптән 20 проценттан) артып киткән торак урынның гомуми мәйданы социаль ипотека буенча тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана торган торакның бер квадрат метры бәясенә артыклык коэффициентын кулланып түләнә.

16. Әгәр дә исәпкә алынганнан соң яшь гаиләнең баласы туса, аның торак урын кыйммәтен түләүгә юнәлдерелә торган дәүләт ярдәменә 200 мең сумга, әмма торак урын өчен түләнмәгән өлеш кыйммәтеннән артмаган күләмдә яки бала туган вакытка төп бурычның түләнми калган суммада хокукы барлыкка килә.

17. Яшь гаиләләр социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ яшь гаиләне исәпкә кую урыны буенча гына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актлары белән билгеләнгән очраклардан тыш) фатир сайлап алу хокукына ия.

18. Яшь гаиләләргә торак бирү конкурс нәтиҗәләре буенча фатир сайлап алуда катнашу тәртибендә гамәлгә ашырыла.

19. Конкурста катнашу өчен шартнамә төзегән һәм бу Тәртипнең 15 нче пунктында билгеләнгән нормативлар нигезендә бирелә торган торак урыны кыйммәтеннән кимендә 10 процент башлангыч кертемне җыйган яшь гаиләләр рөхсәт ителә.

20. Фатир сайлап алу буенча конкурс гражданнар тарафыннан үзләренең булачак фатирлары билгеләү максатларында билгеләнгән квоталар чикләрендә үткәрелә.

21. Конкурста катнашу өчен яшь гаилә шартнамәдә күрсәтелгән индивидуаль номер һәм пароль буенча махсуслаштырылган оешманың «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (алга таба – рәсми сайт) электрон рәвештә заявка тутыра.

Заявкада гражданнар тарафыннан өстенлекне киметү тәртибендә сайлап алына һәм тели торган фатирлар исемлеге билгеләнә. Заявка рәсми сайтта теркәлә.

22. Конкурста җиңүче булып электрон рәвештә билгеләнә торган иң зур рейтингка ия булган яшь гаилә танылa.

23. Яшь гаиләнең рейтингы яшь гаиләнең алдан җыела торган мең сумнардагы акча суммасына тигез булган, аларның махсуслаштырылган оешма счетында булган көннәре санына конкурска йомгак ясау көненә кадәр соңгы 10 көнне кертмичә тапкырланган сан мәгънәсе буларак билгеләнә.

24. Махсуслаштырылган оешманың конкурста җиңүчеләрен билгеләү турындагы карары конкурс йомгаклары турындагы хисапта рәсмиләштерелә. Мәгълүмат рәсми сайтта шәхси биттә чагылдырыла.

25. Конкурс йомгаклары турында хисап расланган көннән 10 эш көне эчендә яшь гаиләләр фатир сайлап алуның якынча беркетмәсенә имза куя.

Яшь гаиләләр торак шартларын яхшырту һәм торак йортны файдалануга тапшыру хокукын раслау шарты белән Махсуслаштырылган оешманың попечительләр советы тарафыннан раслана торган форма буенча фатир сайлап алу беркетмәсе төзелә. Фатир сайлап алу беркетмәсе шартнамәнең аерылгысыз бер өлеше булып тора һәм конкурста җиңүченең сайлап алынган фатирга урнашу һәм аннан файдалану хокукын раслый.

Фатир сайлап алу беркетмәсенә яшь гаиләләр сайлап алынган фатир урнашкан торак йортны файдалануга тапшырган көннән 30 календарь көннән дә соңга калмыйча имза куя.

Яшь гаилә 30 календарь көн эчендә фатир сайлап алу беркетмәсенә имза куймаган очракта, гражданның фатир сайлап алу буенча конкурс йомгаклары һәм фатирны сайлап алуның якынча беркетмәсе гамәлдән чыгарыла.

Объектны файдалануга тапшыру датасы һәм сайлап алынган фатирга күченү мөмкинлеге турындагы мәгълүмат махсуслаштырылган оешма тарафыннан рәсми сайтта объектны файдалануга тапшыру датасыннан 10 календарь көн эчендә урнаштырыла.

26. Сатып алына торган торак урынның бер квадрат метрының башлангыч кыйммәте махсуслаштырылган оешма тарафыннан билгеләнә. Торак урын өчен түләнмәгән өлешнең кыйммәте төзелеп беткән объектны кабул итү акты кабул итү комиссиясе тарафыннан расланган көннән ай саен елына 7 процент (аена 7/12 процент) исәбеннән артып бара.

Россия Федерациясе Үзәк банкының рефинанслау ставкасы кимегән очракта, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты торак урынның түләнмәгән өлеше кыйммәтенә кертелә торган еллык ставкаларны (процентларны) киметү мөмкинлеге турындагы мәсьәләне карый.

27. Торак урынны милеккә сатып алу буенча айлык агымдагы түләүләрне өлешләп түләү 28,5 елга кадәр тәшкил итә.

28. Милеккә өлешләп түләүгә бирелгән торак урыннарны сатып алу буенча айлык агымдагы түләүләр фатирны сайлап алу беркетмәсен рәсмиләштергән вакытка торак урынның сатып алынмаган мәйданына тапкырланган һәм айларда түләүне өлешләп түләү вакытына бүленгән торак урынының бер квадрат метры кыйммәтеннән чыгып исәпләнә.

29. Гариза бирүче фатирны сайлап алу беркетмәсен рәсмиләштергән вакыттан торак урынның гомуми мәйданының түләнмәгән өлеше өчен наем түли.

30. Җирле үзидарә органнары һәм махсуслаштырылган оешма карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.

Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ яшь гаиләләргә торак урыннары бирү тәртибенә
1 нче кушымта

Форма

______________________________________________
(район, шәһәр исеме)
җирле үзидарә органы җитәкчесе
______________________________________________
____________________________________________нә
гражданнан ________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча)
______________________________________________
адресы буенча яшәүче _____________________
(почта индексы,
______________________________________________
тулы адресы, элемтәгә керү өчен телефоны)
______________________________________________
______________________________________________
адрес буенча теркәлгән: ____________________
(почта индексы,
______________________________________________
тулы адресы)
______________________________________________
______________________________________________
______________________________________________
__________________________________________ нән
(көне, ае, елы)

ГАРИЗА

___________________________________________________________________________
(торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ булу сәбәпләрен күрсәтергә)
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________ бәйле рәвештә,

Сездән мине социаль ипотека системасында торак шартларын яхшырту өчен ____ кеше составындагы гаилә белән яшь гаилә буларак исәпкә алуыгызны сорыйм.

Мин һәм минем гаилә әгъзалары җирле үзидарә органнары тарафыннан гаризада һәм анкетада күрсәтелгән мәгълүматларны, аларның сорауларына, шулай ук махсуслаштырылган оешма (Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды) тарафыннан исәпкә алу турындагы мәсьәләне карап тикшерү өчен кирәкле документларны тикшерүгә ризалык бирәбез.

Мин һәм минем гаилә әгъзалары, безне исәпкә алган очракта, гаризада күрсәтелгән мәгълүматлар үзгәргәндә бер ай эчендә алар турында исәпкә алу урыны буенча җирле үзидарә органнарына язма рәвештә хәбәр итәргә тиеш дип кисәтелде.

Мин һәм минем гаилә әгъзалары, гаризада күрсәтелгәннәргә туры килми торган мәгълүматлар ачыкланган очракта, безне закон белән билгеләнгән тәртиптә исәптән төшерүгә риза.

Моның белән мин тиешле салым органнарында һәм күчемсез мөлкәткә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алу органнарында минем керемнәрем һәм милек хокукында минеке булган мөлкәт турындагы мәгълүматларны тикшерергә ризалык бирәм.

Гариза бирүче ________________________________________________ ________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) тулысынча) (имзасы)

Гаиләнең эшкә сәләтле әгъзалары:
1.____________________________________________________________
2.____________________________________________________________
3.____________________________________________________________
4.____________________________________________________________
(гаиләнең барлык эшкә сәләтле әгъзаларының имзалары)

2020 ел, «___» __________

Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ яшь гаиләләргә торак урыннары бирү тәртибенә
2 нче кушымта

Яшь гаиләне социаль ипотека системасында торак шартларын яхшырту өчен исәпкә алу мәсьәләсен карау өчен кирәкле документлар исемлеге

Гражданның җирле үзидарә органы җитәкчесе исеменә гариза;

финанс-шәхси счет күчермәсе;

торак урында яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар санын раслый торган мәгълүматлар;

ордер (найм, поднайм, аренда, субаренда шартнамәсе);

эшчәнлек алып баруны раслый торган документ;

гаиләнең барлык эшләүче әгъзаларының эш урыныннан предприятиенең реквизитларын, гражданның эш урынын, аның вазыйфасын үз эченә алган, оешма җитәкчесе тарафыннан имзаланган һәм оешма мөһере (Россия Федерациясе законнары белән мөһер булу бурычы билгеләнгән очракларда) белән расланган белешмә кәгазе (кәгазьләре) – хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашырганда;

дәүләт органнарының расланган формалары буенча үткән ел өчен керемнәр турында документ;

студентлар билеты яки уку урынын раслый торган документ (укучылар өчен);

стипендия алу турында белешмә кәгазе (студентлар өчен);

пособиеләр алу турында белешмә кәгазе;

торак урынга хокук билгели торган документлар күчермәләре (аренда шартнамәсе, түләүсез файдалану шартнамәсе, бүләк итү шартнамә һ.б.);

Техник инвентарьләштерү бюросы тарафыннан бирелгән торак урынның (фатирның) техник паспорты;

Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;

Техник инвентарьләштерү бюросыннан милектә торак булу яки аны алу буенча алыш-бирешләрне гамәлгә ашыру турында белешмә кәгазе (гариза бирүче гаиләсенең һәр әгъзасына);

гариза бирүченең барлык гаилә әгъзалары өчен паспорт мәгълүматлары (серия, номер, кем һәм кайчан бирелгән), ә балигъ булмаган гаилә әгъзаларына – туу турында таныклык;

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының $66^1$ статьясында билгеләнгән тәртиптә алынган хезмәт кенәгәсенең күчермәсе һәм (яки) хезмәт эшчәнлеге турында тиешле рәвештә расланган мәгълүматлар;

туганлык мөнәсәбәтләрен раслый торган документлар: никахлашу турында таныклык (никахлашуны өзү турында таныклык), бала (балалар) туу турында таныклык, уллыкка (кызлыкка) алу турында суд карары;

гариза бирүченең һәм һәр гаилә әгъзасының ИНН (салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры) күчермәләре.

Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ яшь гаиләләргә торак урыннары бирү тәртибенә
3 нче кушымта

Форма

## Гариза бирүче анкетасы

1. Гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда) ______________________
(тулысынча)
_______________________________________________________________________________________

2. ______________________________________________________________________ адресы буенча яшим
(район, урам, йорт, фатир, бүлмә)
_______________________________________________________________________________ [ | | | ]
(24 бүлек коды)
_______________________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________________
(элемтәгә керү өчен телефон номерын күрсәтергә: өй, эш)

3. Шәхесне таныклый торган документ ___________________________________________________
документ төре
сериясе ___________ номеры __________________________ кем һәм кайчан бирде _____________________
_______________________________________________________________________________________

4. Туган көне __________________________________________________________________________
(көне, ае, елы)
_______________________________________________________________________________ [ | | | ]
(7 бүлек коды)

5. Туган урыны _________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________ [ | | | ]
(шәһәр, район коды)

6. Салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры (ИНН) [ | | | | | | | | | | | | ]
(9 бүлек коды – барлык унике билгене күрсәтергә)

7. Эш белән тәэмин ителеш _______________________________________________________________
_______________________________________________________________________________ [ ]
(әгәр дә гариза бирүче эшләмәсә, эш белән тәэмин ителмәүнең сәбәбен күрсәтергә) (10 бүлек коды)
_______________________________________________________________________________________
(оешма, предприятие, бүлек, уку урынының тулы исемен күрсәтергә)
_______________________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________________

8. Предприятие ИННы ____________________________________________________________________
_______________________________________________ [ | | | | | | | | | ]
(9 бүлек коды)
_______________________________________________________________________________________
(әгәр дә гариза бирүче эшләмәсә, ИНН мәгънәсенә нульләр куела, ягъни эшләмәүче өчен ИНН – 0 000 000 000)

9. Гаилә составы ________ кеше

| Т/с | Фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда) тулысынча | Туганлык мөнәсәбәтләре | Туган көне | Шәхеснең таныклыгы (сериясе, номеры) | Физик затның ИННы | Эш, уку урыны | Эш стажы | Предприятие ИННы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Гариза бирүче | 01 | | | | | | |

10. Соңгы эш урында стажы тәшкил итә ________________________________

________________________________________________ [ | ]

(ел санын күрсәтергә)

11. Гомуми эш стажы тәшкил итә ________________________________

________________________________________________ [ | ]

(ел санын күрсәтергә)

12. Мин һәм минем белән яшәүче гаилә әгъзалары торак мәйданын (өлешен) милек хокукында билибез ________________________________________________

(нинди, кем, кайда, нигезләрен күрсәтергә )

________________________________________________

________________________________________________ [ ]

(20 бүлек коды)

13. Найм шартнамәсе буенча ________________________________

(төгәл кем икәнен күрсәтергә)

________________________________________________

________________________________________________

| Т/с | Гариза бирүченең һәм гаилә әгъзаларының фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда) | Туганлык мөнәсәбәтләре | Язылу датасы | Аерым финанс-шәхси счет булу | Мәйданы (гомуми/торак) |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | | | | | |
| 2. | | | | | |
| 3. | | | | | |

14. Милек хокукында ________________________________

(төгәл кем икәнен күрсәтергә)

| Т/с | Фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда) тулысынча | Туганлык мөнәсәбәтләре | Адресы | Торак хокуклары объекты (коды) | Мәйданы (гомуми/торак) | Милек турында таныклык буенча теркәлү датасы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | | | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 2. | | | | | | |
| 3. | | | | | | |
| 4. | | | | | | |
| 5. | | | | | | |

15. Соңгы биш елда торак шартларын начарайтуга китергән торак урыннар белән гражданлык-хокукый алыш-бирешләр гариза бирүче һәм аның гаилә әгъзалары тарафыннан түбәндәге сәбәпләр аркасында үткәрелде ______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

(нинди икәнен күрсәтергә)

16. Гаиләнең бер әгъзасына гомуми мәйдан белән тәэмин ителешнең җыелма дәрәҗәсе ___________________

______________________________________________________________________ ☐

(гаиләнең бер әгъзасына күпме кв.метр туры килүен күрсәтергә) (15 бүлек коды)

17. Били торган фатирның тибы ______________________________________________

(фатир тибын күрсәтергә: бүлмәләр саны)

______________________________________________________________________ ☐

(төзекләндерү стандартын күрсәтергә) (23 бүлек коды)

______________________________________________________________________

18. Банкларның һәм башка оешмаларның кредит акчаларын теләсә нинди кертемнәргә куллану ___________

______________________________________________________________________ ☐

(фатир, техника сатып алу, уку өчен түләү һ.б.)

(әйе 1, юк 2)

19. Айлык түләүләр суммасы ______________________________________________

(түләүләрнең төгәл суммасын күрсәтергә)

______________________________________________________________________

20. Түләүләрнең срогы тәмамлану ______________________________________________

21. Тутырылган декларация нигезендә бер кешегә исәпләнгән гаиләдә айлык җыелма керем тәшкил итә

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________ ☐

(22 бүлек коды)

(салым инспекциясе раслаган декларация формасы гражданнарны исәпкә алу турындагы мәсьәләне карау өчен кирәкле документлар исемлегенә теркәлә)

22. Беренчел кертемне (пай туплау) кертү мөмкинлеге ______________________________________________

______________________________________________________________________ ☐

(33 бүлек коды)

______________________________________________________________________

(әгәр дә мөмкинлек булса, күпме (%) икәнен күрсәтергә: 10%, 20%, 30%, 30 проценттан артык)

______________________________________________________________________

23. Ташламалар категориясе ______________________________________________

______________________________________________________________________ ☐

(бар/юк (астына сызарга) (36 бүлек коды)

(ташламалар нигезләвен, ташламалар төрен күрсәтергә:

һәлакәтләрдә катнашучылар, чернобыльчеләр, күпбалалылар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар

сәламәтлек торышы буенча, тузган торак, башкалар)

24. Эш белән тәэмин итү өлкәсендә гражданнар квоталары категориясе ______________________________

(37 бүлек коды)

(гариза бирүченең кайсы гражданнар категориясенә керүен күрсәтергә)

25. Таләп ителә торган торак төре (теләгән) ______________________________________________

(35 бүлек коды)

Бу гариза бирүче анкетасындагы мәгълүматларның түбәндә күрсәтелгән датага дөрес һәм төгәл булуын раслыйм.

Гариза бирүче ______________________________________________________ __________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда) тулысынча) (имзасы)

Гаиләнең эшкә сәләтле әгъзалары:
1.____________________________________________________________
2.____________________________________________________________
3.____________________________________________________________
4.____________________________________________________________
(гаиләнең барлык эшкә сәләтле әгъзаларының имзалары)

2020 ел, «___» __________